**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул.Дмитрова, д.2, с.Ютаза, 423962**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**Дмитров урамы, 2 йорт, Ютазы авылы, 423962**

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» ноябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге составына керүче Ык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 14 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 28 ноябрендә 14 сәг.00 минутта Ык торак пунктының Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ык торак пункты, Яшел урам, 6 санлы йорт яны адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне үтәү буенча хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

– Ык торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл төзү: вак таш сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, салу, проект-смета документациясен әзерләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетына Ык торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм

коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина